| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БУРНАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРНАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18.07.2024** **№106**

**Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип танунын өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына туры китереп, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Борнакавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммасының аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче, түбәндәге нигезләр буенча түләү һәм (яисә) түләтү мөмкин булмаган суммалар өлешендә түбәндәгеләр түләтүгә өметсез дип таныла:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычы булу;

2) оешмаларда яисә шәхси эшмәкәрләрдә 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнә торган бурыч булу;

3) физик затлар мөлкәтенә салым буенча Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар узганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу;

4) физик затлардан җир салымы буенча Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар узганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар түбәндәгеләр:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә физик затны салым органында исәптән төшерү турында белешмә;

в) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау хакында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) шәхси эшкуар статусын югалткан оешма, шәхси эшкуар, физик затның бурыч суммасы турында исәпкә кую урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) салым бетерелүгә нигез булып торган норматив хокукый акт турында белешмә (исеме, датасы, номеры);

3) әлеге Карарның 1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган күләмдә бурыч барлыгы турындагы белешмәсе;

4) әлеге Карарның 1 пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган күләмдә бурыч барлыгы турындагы белешмәсе.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге Советының 2023 ел, 28 нче апрель "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" 78 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлеге җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Борнак авыл җирлеге Советы башлыгы
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Борнак авыл җирлеге Советы рәисе Ш.М.Хабибуллин